**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Урсаевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл**
**җирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентябрь 2018 ел № 12

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"2019 елда үзара салым кертүгә Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән Сез килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

3) халыкны су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү уртак чикләрендә оештыру;

4) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;

5) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

5) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

ТР. Азнакай районы,Урсай авылы, Үзәк ур., 65;

ТР, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури ур., 31

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.2. Настоящее постановление подлежит обнародованию путем размещения на:

Башлык: И.А.Абдуллин